РАСЛЫЙМ
Казан шәһәре
Киров районының
"7нче номерлы балалар бакчасы"
мәктәпкәчә муниципаль бюджет
белем бирү учреждениесе мөдире
____________Биктова А.Н.
«9» август 2021 ел.

**«Туган тел – халык байлыгы»-**
**«Родной язык – богатство народа»**
**республикакүләм онлайн шигырь укучылар конкурсы**
**НИГЕЗЛӘМӘСЕ**

«Туган тел – халык байлыгы» - «Родной язык – богатство народа» республикакүләм онлайн шигырь укучылар бәйгесе Татарстан Республикасында Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы уңаеннан үткәрелә.

**Конкурсның оештыру комитеты:**

- Казан шәһәре Киров районының «Билингваль катнаш төрдәге 7нче номерлы балалар бакчасы" мәктәпкәчә муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе;
- «Татнетны үстерү фонды" коммерцияле булмаган оешмасы.

**1. Гомуми нигезләмә.**

Нигезләмә Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче 3 яшьтән алып 7 яшькә кадәр балалар арасында үткәрелә торган «Туган тел – халык байлыгы» - «Родной язык – богатство народа» республикакүләм онлайн шигырь укучылар бәйгесенең (алга таба – Бәйге) максатларын һәм бурычларын, шартларын һәм үткәрү тәртибен билгели.

**2. Бәйгенең максатлары һәм бурычлары.**

**Максат:** Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның иҗади мөмкинлекләрен ачу, туган телгә һәм Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче башка халыклар теленә, әдәбиятына, шигъриятенә, гореф-гадәтләренә һәм мәдәниятенә кызыксыну уяту.

**Бәйгенең бурычлары:**

- Туган телгә һәм Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче башка халыклар теленә, мәдәниятенә һәм гореф-гадәтләренә мәхәббәт һәм әхлакый-патриотик хисләр тәрбияләү.
- Сәнгатьле уку-башкару осталыкларын камильләштерү.
- Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны нәфис сүз осталыгына җәлеп итү.
- Сәнгатьле сөйләм һәм башкару осталыгы күнекмәләрен формалаштыру.
- Уртак иҗади эшчәнлек нәтиҗәсендә педагоглар, ата-аналар һәм балаларның үзара хезмәттәшлек нәтиҗәлелеген күтәрү.

## 3. Бәйгедә катнашучылар

Бәйгедә мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләр, өстәмә белем бирү учреждениеләре, белем бирү оешмаларына йөрмәгән балалар катнаша ала.

**Бәйгедә яшь төркемнәре һәм категорияләре:**

- I төркем: 3 яшьтән 4 яшькә кадәр (кертеп);
- II төркем: 5 яшьтән 7 яшькә кадәр (кертеп).

**Бәйге номинацияләре**:

- Соло
- Кече формалар (дуэт, трио һәм 5 балага кадәр булган кече төркемнәр)

## 4. Бәйгенең шартлары

Катнашучыларга түбәндәгеләр тәкъдим ителә:

- кайсы да булса шагыйрьнең бер шигыре яисә нинди дә булса шигъри әсәрдән өзек ике телдә – рус һәм Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче башка бер халык телендә сәнгатьле итеп яттан сөйләп тәкъдим ителергә тиеш;
- 30 секундтан 3 минутка кадәр дәвамлылыктагы әлеге чыгыш видео форматында чыгыш ясаган катнашучының әти-әнисенең Инстаграм яисә ВКонтакте аккаунтында урнаштырыла. Чыгыш вакытында паузалар һәм кадрлар алышыну булмаска, ә бәйгедә катнашучы һәрвакыт кадрда булырга тиеш;
- бер видеоязмада бер әсәр ике телдә яңгырый;
- әсәрнең темасына туры килерлек атрибутлар, музыкаль бизәлеш һәм башка чаралар кулланырга мөмкин;
- видеоязма тасвирламасында бәйгене оештыручыларның аккаунтларын билгеләү мәҗбүри (Инстаграм: @tatnet.fond, @ ds7_altin_hiyal; ВКонтакте: @tatnet); катнашучының исем-фамилиясе, яше һәм яшәгән районы күрсәтелә. Гаризада, катнашучыларның теләгенә карап, белем бирү учреждениесе яисә әти-әнисенең исем-фамилиясе язылырга мөмкин;
- бер катнашучыдан бер генә гариза кабул ителә

Иң яхшы дип табылган чыгышлар – җиңүчеләрнең видеоязмалары Бәйгене оештыручыларның социаль челтәрләрендә урын алачак. Үзенең видеоматериалын оештыручылар аккаунтын билгеләп социаль челтәрдә урнаштырган катнашучы, әлеге нигезләмә белән танышкан һәм шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә рөхсәт биргән дип санала (кушымта 1).

## 5. Бәйгене үткәрү срогы һәм тәртибе

Бәйге 2021 елның 9 нчы августыннан 31 нче августына кадәр үткәрелә:

- гаризалар (Бәйгегә материалларны урнаштыру мөмкинлеге) - 20нче августка кадәр (кертеп);
- җиңүчеләрне билгеләү – 2021 елның 21 нче августыннан 22 нче августына кадәр;
- бүләкләү - 2021 елның 31 нче августыннан да соңга калмый башкарыла.

Гаризалар шулай ук (теләк буенча), видеоматериалга сылтаманы күрсәтеп, : lrlz7@mail.ru электрон почта адресына да җибәрелергә мөмкин.

**6. Бәяләү критерийлары:**

6.1. Чыгыш ясау дәрәҗәсе 5 баллы шкала буенча бәяләнә (һәр критерийга 1дән 5кә кадәр балл куела). Бәяләгәндә түбәндәгеләр исәпкә алына:

- әсәрнең зурлыгы һәм яттан белү дәрәҗәсе;
- башкару осталыгы;
- сайланган әсәрнең баланың яшенә туры килүе;
- сәнгатьле һәм аңлаешлы сөйләм;
- әсәрне оригиналь рәвештә тәкъдим итү;
- чыгышның Бәйге таләпләренә туры килүе;
- костюмнар һәм өстәмә реквизитлар куллану.

6.2. Гомуми бәя барлык жюри әгъзалары тарафыннан куелган баллар суммасына карап билгеләнә. Бәйге җиңүчеләренә **Лауреат һәм 1, 2, 3 дәрәҗә Дипломант** исемнәре бирелә.

**7. Жюри**

Жюри составы:

- Гатауллин Раил Мәүлет улы, "Татнетны үстерү фонды" коммерцияле булмаган оешмасының учредителе һәм башкаручы директоры;
- Гилазова Альбина Мансур кызы, Киров һәм Мәскәү районнары буенча "Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының мәгариф идарәсе" муниципаль казна учреждениесе мәгариф бүлегенең җитәкче урынбасары;
- Биктова Алсу Нияз кызы, Казан шәһәре Киров районының «7нче номерлы балалар бакчасы" мәктәпкәчә муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе мөдире;
- Ситдикова Ләйсән Зөфәр кызы, Казан шәһәре Киров районының «7нче номерлы балалар бакчасы" мәктәпкәчә муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе мөдир урынбасары;
- Каменева Лилия Рәис кызы, Казан шәһәре Киров районының "7нче номерлы балалар бакчасы" мәктәпкәчә муниципаль бюджет белем бирү учреждениесы өлкән тәрбиячесе;
- Гатауллина Гөлнара Равил кызы, Казан шәһәре Киров районының «7нче номерлы балалар бакчасы" мәктәпкәчә муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе татар теле тәрбиячесе.

**8. Бәйге җиңүчеләрен бүләкләү**

Жюри составы тарафыннан ачыкланган җиңүчеләр һәм Бәйгедә катнашучылар номинацияләр буенча **электрон дипломнар** белән бүләкләнә. Бәйгедә катнашучыларны әзерләгән педагоглар һәм ата-аналар **электрон Рәхмәт хатларына** ия булачак. Һәр катнашучыга документлар социаль челтәрләр аша 2021 елның 31 нче августыннан да соңга калмыйча җибәреләчәк. Бәйге нәтиҗәләре Татнетны үстерү фондының (https://tat-i.net, https://instagram.com/tatnet.fond) һәм

Казан шәһәре Киров районы «Билингваль катнаш төрдәге 7нче номерлы балалар бакчасы" мәктәпкәчә муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең (https://edu.tatar.ru/kirov/org6882, https://instagram.com/ds7_altin_hiyal). сайтларында һәм социаль челтәрләрдәге аккаунтларында яктыртылачак.

**9. Белешмәләр өчен**

Бәйге белән бәйле бөтен сораулар буенча телефон: **89046652580 (Каменева Лилия Раисовна)**, эл.почта: lrlz7@mail.ru

Приложение 1

Согласие на обработку персональных данных и размещение конкурсной работы в сети интернет

Я, ________________________________________________________________________

подтверждаю согласие на участие в
дистанционном конкурсе чтецов
«Туган тел – халык байлыгы»
«Родной язык – богатство народа»

Подтверждаю правильность изложенной в Заявке информации.

В соответствии с Федеральным законом Российской Федерации от 27.07.2006 г. 152-ФЗ «О персональных данных», даю согласие на обработку своих персональных данных в рамках организации и проведения конкурсных мероприятий, а именно:

1. Разрешаю зарегистрировать в базе данных участников конкурсных мероприятий путем записи персональных данных участника;
2. Разрешаю в рамках организации и проведения указанных мероприятий вести обработку персональных данных с использованием средств автоматизации или без использования таких средств;
3. Разрешаю дальнейшую передачу персональных данных в государственные органы с целью совершения действий в соответствии Законами Российской Федерации;
4. Разрешаю передачу моих персональных данных третьим лицам (организациям), которые в соответствии с договором с Организатором Конкурса осуществляют организационные мероприятия;
5. Разрешаю в рамках организации и проведения указанных конкурсных мероприятий распространение персональных данных (фото, Ф.И.О., общественная деятельность) путем размещения в Интернете, буклетах и периодических образовательных изданиях с возможностью редакторской обработки, а также в целях подготовки раздаточных материалов, листов регистрации, листов оценки работ экспертов, итоговых бюллетеней и каталогах;
6. гарантирую соблюдение авторских прав при подготовке материалов, представленных на Конкурс.

При этом:

1. Организатор Конкурса гарантирует обеспечение сохранности базы данных участников от несанкционированного доступа.
2. Оператор Конкурса гарантирует, что персональные данные участника Конкурса будут использованы только для целей организации и проведения указанных конкурсных мероприятий.
3. Согласие на обработку персональных данных действует до момента завершения совершения всех действий, связанных с организацией и проведением указанных мероприятий Конкурса в соответствии с Положением об их проведении.

Подпись_________________/________________________ Дата _______________

Ф.И.О.